**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЗУР КҮККҮЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел,15 июль №194

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Зур Күккүз авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Күккүз авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Күккүз авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 августындагы 91 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Зур Күккүз авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Зур Күккүз авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына түбәндәге адрес буенча урнашкан территорияләрне зоналаштыру өлешендә:

1) Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Зур Күккүз авыл җирлеге (кадастр номеры 16:08:040702:100) Р1 зонасыннан (табигый ландшафтлар зонасы) СХ1 зонасына (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасы) (кушымта);

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Зур Күккүз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зур Күккүз авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) А.И. Хафизовка йөкләргә.

**Зур Күккүз авыл җирлеге Башлыгы –**
**Зур Күккүз авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ф. Низамова**

Кушымта

